| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**24.12.2024** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№5372** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 08 декабрендәге «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында» 3393 номерлы карары белән расланган, административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле Зеленодольск муниципаль районы вазыйфаи затлары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 26 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, ««Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.2 һәм 3.16 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында»» 2024 елның 25 октябрендәге 86-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ**:

1.Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 08 декабрендәге «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында» 3393 номерлы карары белән расланган, административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле Зеленодольск муниципаль районы вазыйфаи затлары исемлегенә үзгәрешләр кертергә:
1.1. түбәндәге эчтәлекле 21.1 пункт белән тулыландырырга:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 21.1 | **Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.15.1 статьясы** | Җәмәгать урыннарында товарларны һәм хезмәтләрне көчләп тагу | - «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының административ-техник инспекциясе идарәсе» МКУ башлыгы урынбасары;<br>- «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының административ-техник инспекциясе идарәсе» МКУ баш |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | белгече;<br>- «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының административ-техник инспекциясе идарәсе» МКУ әйдәп баручы белгече;<br>- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать иминлеген тәэмин итү бүлеге башлыгы;<br>- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать иминлеген тәэмин итү бүлеге баш белгече;<br>- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать иминлеген тәэмин итү бүлегенең әйдәп баручы белгече;<br>- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының кулланучылар базары бүлеге башлыгы;<br>- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының кулланучылар базары бүлеге башлыгы урынбасары;<br>- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының кулланучылар базары бүлеге баш белгече. |

1.2. Пункт 22 пункты яңа редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 22. | **Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.16 статьясы** | Түләүле муниципаль парковкалардан (парковка урыннарыннан)файдалану тәртибен бозу | - «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының административ-техник инспекциясе идарәсе» МКУ башлыгы урынбасары;<br>- «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының административ-техник инспекциясе идарәсе» МКУ баш белгече;<br>- «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының административ-техник инспекциясе идарәсе» МКУ әйдәп баручы белгече;<br>- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать иминлеген тәэмин итү бүлеге башлыгы;<br>- Зеленодольск муниципаль |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | районы Башкарма комитетының җәмәгать иминлеген тәэмин итү бүлеге баш белгече;<br>- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать иминлеген тәэмин итү бүлегенең әйдәп баручы белгече. |

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин